**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘРКӘТӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ЧЕРЕМШАНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН СОВЕТ БЕРКЕТ-КЛЮЧЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**423106, БӘРКӘТӘ АВЫЛЫ, ЛЕНИН УРАМЫ, ЙОРТ 76 "а"**

**тел.+7(84396) 2-64 -66 тел./факс +7(84396) 2-64-66**

**423106, СЕЛО БЕРКЕТ- КЛЮЧ, УЛИЦА ЛЕНИНА, ДОМ 76 «а»**

**№78** **31.01.2023 ел**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлеге Советы

**КАРАРЫ**

Халыкка транспорт хезмәте күрсәтү һәм район чикләрендә җирлекләр арасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өчен шартлар тудыру буенча вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2006 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенең 2 абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Бәркәтә авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге башкарма комитетына Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының халыкка транспорт хезмәте күрсәтү һәм район чикләрендә җирлекләр арасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өчен шартлар тудыру буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы вәкиллекле органы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләр өлешен тапшыру турында килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны ТР Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлегенең даими комиссиясенә йөкләргә.

Бәркәтә авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Р.М.Сибгатуллин